ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**11 сентябрь, 2023 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№31-04**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, 2023 елның 3 февралендәге 2 номерлы-ТРЗ «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Актаныш муниципаль районы Советының 15.09.2018 № 30-07, 15.04.2019 № 37-06, 06.08.2019 № 39-09, 28.04.2020 № 46-08,12.08.2020 № 47-07, 02.11.2020 № 02-09, 08.02.2021 № 07-08,15.11.2021 №12-11, 05.07.2023 №30-08), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда:

а) 14.5 өлештә «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

б) 14.7 өлештә «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяда:

а) 15.6 өлештә «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 15.6.1 өлеш өстәргә:

15.6.1 муниципаль хезмәткәрнең әлеге статьяның 15.6 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыруы, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

3) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 30.1.1 өлеш өстәргә:

30.1.1. Мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук андый бурычларны үтәмәү очрагында коррупциягә каршы тору максатында әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки аны җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның

25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә, аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип таныла.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.Р. Вахитовка йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов